СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.05.2023 п.г.т. Алексеевское № 72

**Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар итте:**

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йәварисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, йә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, йә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

2) салым түләүче гражданның-физик затның стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән өч еллык срокның тәмамлануы;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

-Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 11.07.2017 ел,№ 98 карары.

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 11.07.2017 ел, № 99 «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча недоимканы һәм пенялар буенча бурыч түләүләрен алуны һәм исәптән чыгаруны өметсез дип тану тәртибе турында»карары

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/),Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары В.В.Увакинага йөкләргә.

**Алексеевск шәһәр җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С. А. Демидов**